## Газинурлар белән бер сафта

*(Габдрахман Әпсәләмовның сугыш темасына язылган әсәрләре буенча әдәби-музыкаль кичә)*

Бөек Җиңүнең 65 еллыгы якынлашу уңаеннан Габдрахман Әпсәләмовның сугыш темасына язылган әсәрләреннән әдәби-музыкаль кичә уздырырга мөмкин. Кичәнең максаты – укучыларны Г.Әпсәләмовның әсәрләре, иҗаты белән тирәнтен таныштыру.

*Зал чәчәкләр белән бизәлә. Әдипнең әсәрләрен һәм аның турында материаллар туплап китап күргәзмәсе куела. Диварга Г.Әпсәләмовның хәрби киемнән төшкән фоторәсеме, әсәрләрендә кулланылган мәкальләре (батырлык турында) эленеп куела. Кичәне 2 кеше алып бара. Әсәрдән өзекләрне 1 укучы укый. Кичә ахырында укучылар арасында викторина үткәрергә, кроссворд төзеп чишәргә мөмкин.*

*Залдагы экранда мультимедиа проекторы аша сугыш күренешләре (тавышсыз гына) күрсәтелә. Әлеге күренешләрне интернеттан түбәндәге адрес белән таба аласыз:*

http://www.youtube.com/
watch?v=SDHel_MOwTo&feature=related
(Великая Отечественная Война )
http://www.rian.ru/video/20090622/174999469.html
(Хроника Великой Отечественной войны. Взгляд назад)
http://www.youtube.com/watch?v=HcDa6Hb1nPw
(Священная война. Песня с кадрами кинохроники)
http://www.youtube.com/
atch?v=pfJGtWRPedE&feature=related
(Сражение у стен Столицы. Московская битва.)

*Магнитофон аша әкрен генә симфоник оркестр башкаруында «Моя республика=Минем республикам» көе уйнатыла. Шул көй уйнаган вакытта укучы «Газинур» романыннан өзек укый.*

«Күзләрен зур итеп ачып, күңеле нәфрәт белән ташыган хәлдә, Газинур үкереп торган дошман пулеметына карый. Ул якын гына, ләкин аңа барып җитәргә мөмкин түгел. Аның утлы бугазын тыгарлык бер кәч тә юк шикелле. Газинур күзләрен



каплаган каскасын юеш кулы белән күтәрә төште. Артына борылып карамады, ләкин командирның гына түгел, бөтен батальонның аңардан кыю хәрәкәт көткәнен сизенде. Тик буш кул белән ни эшли ала соң ул? Газинур кулын күкрәгенә китерде. Атылып чыгардай типкән йөрәге янында, гимнастерка кесәсендә, Александр Матросовның рәсеме!

– Саша… –диде ул кинәт әкрен генә. – Рәхмәт…

Газинурның кыска тормышында бөек бер минут иде бу. Ул, үзе турында бөтенләй онытып, яткан җиреннән сикереп торды. Моңарчы кара кургашын тутырргансыман авыр гәүдәсе кинәт җиңеләеп киткәндәй булды. Әйтерсең, аңа канатлар чыкты.

Газинур дзотка таба йөгерә башлады. Фашист пулеметы, котырынуының соңгы чигенә җитеп, һаман да үкерә иде. «Юк, туктата алмассың!»

Шунда бөтен батальон тынып калды. Сержантның нәрсә эшләргә теләве хәзер һәркемгә ачык иде. Ничәмә-ничә сугышларны башларыннан кичергән, ничәмә-ничә тапкыр үлем белән бугазга-бугаз килеп якалашкан сугышчылар таң калды, йөрәкләре тибүдән тукталгандай булды. Ничек йөрәкләре тибүдән тукталмасын? Аларның күз алдында Сталин солдаты үлем белән үлемсезлек арасын үтә, аларның күз алдында большевиклар партиясе тәрбияләп үстергән гади совет кешесе буыннардан буыннарга калырлык, телләрдән төшмичә легендалар итеп сөйләрлек, җырларда җырланачак батырлык эшли иде.

Ажгырып торган амбразурадан берничә адымда Газинур кинәт тукталып калды. Язгы аяз күктә, еракта-еракта, бөдрә ак болытлар йөзә иде. Кояш нурлары аларны үтәдән-үтә яктырткан, алар шундый җиңелсыман, өрсәң тузганак кебек, очып китәр төсле. Үзләре шундый ак, беренче яуган кар да андый ак булмый, бугай…

Кайда, кайчан күргән иде соң Газинур шундый ак һәм җиңел болытларны?

Фашист пулеметы һаман үкерә. Артык бер генә минут та көтәргә ярамый. Ул атып торган һәр секунд безнең җиңүебезне тоткарлый, уннарча сугышчыларның гомерләрен юк итә.

Газинурның карары нык. Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк.

«Туган ил өчен… Сталин өчен…» – дип уйлады ул һәм шушы соңгы сулышында үзе өчен иң кадерле, иң якын булган

балаларын, хатынын, карт әтисен, җаннан артык күргән дусларын, сөекле һәм газиз Ватанын исенә төшерде...». *(Музыка тына.)*

**1 а.б.**
Халкыбызның фашизмны җиңүенә тиздән 65 ел тула.

Сугыш һәр гаиләгә кайгы-хәсрәт, күз яше алып килде, илебезгә исә моңарчы күрелмәгән зур корбаннар, матди зыян китерде.

Бөек Ватан сугышы гитлерчылар фашизмына каршы илебезнең иреген, бәйсезлеген саклап калу өчен көрәштә ватандашларыбызның батырлыгын, кыюлыгын, мәгърурлеген күрсәткән дәлил дә булды.

Татарстан бу гомуми көрәшкә үзеннән зур һәм сизелерлек өлеш кертте – фронтка меңләгән самолет, миллионлаган снаряд, хәрби кием-салым, корал, азык-төлек, икмәк озатып торды.

Татарстан халкы сугышта зур югалтуларга дучар булды. Аның 350 меңнән артык егет һәм кызлары сугыш кырларында ятып калды.

Халкыбызның батыр уллары-кызлары турында татар әдипләре күпсанлы әсәрләр иҗат итте. Бүген без сезнең белән Габдрахман Әпсәләмовның Бөек Ватан сугышы елларындагы иҗаты, эшчәнлеге, әсәрләре белән танышырбыз.

**2 а.б.**
Габдрахман Әпсәләмов 1911 елның 28 декабрендә элекке Пенза губернасының Краснослободск өязе (хәзерге Мордовия Республикасының Рыбкино районы) Иске Аллагол авылында дөньяга килә. Әнисе Зөһрә һәм әтисе Сафа абый алты бала тәрбияләп үстерәләр, Габдрахман исә иң өлкәне була.

**1 а.б.**
Гади авыл малае үзенең киләчәктә зур шәхес буласын уена да китерә алмый әле. Ул әле дөньяда язучы дигән затлар барлыгын да белми. Ишле татар гаиләсендә үскән бик тәртипле, тырыш, гадәттән тыш тыйнак бер бала гына әле ул. Туган як табигатенә балаларча гашыйк, шул як халыкларының җырларын, моңнарын тыңлап, әкият-бәетләрен ишетеп үскән яшүсмер ул. Мишәр халкының туй йолалары, кыз елату, килен



төшерү һ.б. үзенчәлекле җырлар, такмаклар аның күңеленә шул чакларда мәңге онытылмаслык булып кереп кала.

**2 а.б.**
Язучының әнисе ягыннан абыйсы Ибраһим гомерлек солдат булган. Бала, дөньясын онытып, шул солдат хикәяләрен тыңлый, хыялында аның белән бергә окопта ята, атакага бара, пулеметтан ата... Гади генә сүзләр белән дәһшәтле сугыш күренешләрен бирә алган солдатның хикәяләре булачак язучы хәтерендә сакланып кала. Автобиографиясендә ул болай яза: «Хәзер уйлап карыйм да, минем иҗатымдагы сугыш романтикасы орлыклары шуннан шыталар түгелме, дип куям. Билгеле, үзем сугышта катнашмасам, бу балалык тәэсирләре сүнгән дә булырлар иде, үзем бөтенләй яңа шартларда сугышта булгач, күрәсең, карт солдатның тылсымлы хикәяләре минем йөрәгемдә чәчәк атканнар.»

**1 а.б.**
Булачак язучының үсмер чоры һәм яшьлек еллары Мәскәүдә үтә. Ул Нариманов исемендәге татар мәктәбендә укый.

Беренче әдәби дәресләрне дә Габдрахман Мәскәүдә ала. Ул татар китапханәсендә Муса Җәлил җитәкчелек иткән әдәби түгәрәккә йөри. Хикәяләр һәм пьесалар яза башлый. 1937 елда «Совет әдәбияты» журналында яшь әдипнең «Маһинур» исемле хикәясе басылып чыга.

**2 а.б.**
1938 елның җәендә Г.Әпсәләмов Казанга килә. Казанда ул татар язучылары белән якыннан таныша, яшь шагыйрьләр белән аралаша.

**1 а.б.**
Г.Әпсәләмов 1941 елның августында сугышка китә. Башта Карелия фронтының диңгез бригадасы составында миномет расчеты командиры, аннары, 1943 елның җәеннән 1945 елның маена кадәр, шул ук фронтта чыккан «Ватан өчен сугышка» дигән газетаның җаваплы секретаре булып хезмәт итә. 1945 елның җәеннән 1946 елның апреленә кадәр ул Ерак Көнчыгыштагы «Сталин сугышчысы» исемле фронт газетасы редакциясендә эшли.

**2 а.б.**

Сугышта да ул язу эшеннән туктамый. «Совет әдәбияты» журналында аның хикәяләре, очерклары басылып чыга. Атышлар туктап торган арада көндәлегенә тотына. Ул көндәлекләрдә, үзе күргән һәм кичергән хәлләрдән тыш, сугышчыларга килгән хатларның эчтәлеген дә теркәгән.

Ә хәзер Г.Әпсәләмовка дусты, каләмдәше Ибраһим Газидан килгән хаттан өзек укып китәбез. *(Укучы хаттан өзек укый.)*

«Әпсәләм!

Исән-сау әйләнеп кайтуыңны телим.

«Икенче гомер» һәм «Көндәлек дәфтәр»еңне алдык; журналның 7 санына («Совет әдәбияты») керәләр. Хикәяң әйбәт: тормыш ароматы килеп тора, көндәлегең дә бик ошады. Дәвамын җибәрә алсаң, гаҗәп яхшы булыр иде. Кыскасы, гел язып тор: кыска-кыска хикәяләрме, просто впечатлениеләрме, эпизод сыман нәрсәме – барысын да җибәр.

Безнең иптәшләр хәзер биредә бик аз: Казандагылары да уборкага китеп бетте, мин журналда калып торам. Быел игеннәрне җыеп алу шәһәр халкы өстендә.

Әдәбият дөньясы әкренләп яши. Әкренләп, чөнки бик күп кеше китте. Кайберләре бер нәрсә дә язмыйлар, ләкин язган кешеләрдән яхшы әсәрләр килә: фронт, үлемнең якын булуы иптәшләрнең тойгыларын үткенәйтә, яшәү теләген көчәйтә һәм, гомумән, кешенең мораль көчен ныгыта булса кирәк – яхшы, кайнар тойгылы нәрсәләр яза.

Йә, хуш әлегә! Вакыт таба алсаң, хат яз. Без, мондагылар, сезне һәрвакыт истә тотабыз; сезнең сау-сәламәт булуыгызны ишетү – безгә зур бәйрәм. Шуңа күрә хат язгалап тор.»

Сәлам белән Ибрай Гази
10.VII.1942

**1 а.б.**

«Ватан өчен сугышка» һәм «Сталин сугышчысы» исемле фронт газеталарының редакторы урынбасары Бари Корбановның «Хәрби журналист» исемле мәкаләсендә каты бәрелешләрдә яраланып яңадан сафка баскан Г.Әпсәләмов турында кызыклы фактлар китерелә:



«1943 елның язы. Яктылыгы ягыннан әллә ни аермасы булмаган төн белән көнне бергә ялгап, газетабызның чираттагы санын чыгарырга әзерләнеп утырабыз.

Шулай мәш килеп йөргәндә, бүлмәбезнең ишеген киң итеп ачып, өстенә шактый таушала төшкән шинель кигән, җилкәсенә яшькелт солдат капчыгы аскан, яше утыз-утыз берләр тирәседер, ачык йөзле сержант килеп керде. Күптән көткән кешебез Габдрахман Әпсәләмов иде.

– Ягез, туганнар, урнашыйм да, мин дә эшли башлыйм, – диде Габдрахман.

...Аның җилкәсендә асылынып килгән теге капчыгына да... алмашка кия торган күлмәгенә төрелгән кульязмалар, киләчәге өчен бик кыйммәтле булачак көндәлекләр язылган дәфтәр салынган иде.

«Алтын йолдыз» романын кем генә укымады икән дә, кем генә шул әсәрдә күрсәтелгән Ватан сугышы геройлары белән горурланмады һәм аларны китабына кертүче авторга рәхмәт әйтмәде икән!

Габдрахман Әпсәләмов редакциягә килеп урнашкач та теге капчыгыннан, язу тулы дәфтәре белән бергә, булачак романның инде языла башлаган һәм өлгереп килгән парчаларын тартып чыгарды, бөкләнгән битләрен кулы белән кадерләп тигезләде һәм безгә укыды. Өзекләр безне нык тәэсирләндерде. Фикеребезне әйттек, әсәрне дәвам иттерүен сорадык.»

**2 а.б.**

Г.Әпсәләмовның фронтта язган хикәя һәм очерклары 1944 елда «Төньяк балкышы» исемле җыентык булып басылып чыга.

*(Магнитофон аша әкрен генә Рөстәм Яхинның Муса Җәлил сүзләренә язылган «Соңгы җыр»ы уйнатыла. Укучы «Төньяк балкышы» әсәреннән өзек укый.)*

«Тышта яз. Юллар каралган. Аяк астында кар сулары. Һава күңелдә әллә нинди нечкә хисләр уята торган тәмле сагыз исе белән тулган. Кайдадыр бер читтә пулемет йөткерә, авыр тупларның ерактагы тонык гөрселдәүләре ишетелә.

Түбәләренә яшел чыршылардан яшел шалашлар эшләнгән землянкалар. Алар янында автоматчиклар сафка тезелгәннәр. Алга чыгып баскан дежурный, күзләрен сафлар буйлап йөртеп

чыга да, киерелә төшеп, бөтен тавышы белән:

– Рота, смир-р-но! – дип кичке проверканы башларга команда бирә.

Дежурныйның ачык тавышына урман эчләреннән көчле яңгырау җавап бирә. Ул, үз тавышының мәһабәтлегенә үзе горурлангандай, тамагын кырып ала да, кулындагы тар кәгазьне балкыш ягына борып, фамилияләрне кычкыра:

– Веденин Василий!

– Мин.

– Мещеряков Анатолий!

– Мин.

– Төхфәтуллин Ибраһим!

– Мин.

– Әнвәров Шамил!

– ...

Бер генә секунд тынлык. «Мин» дигән ашыгыч тавыш ишетелми. Сугышчылар бу исемне һәр көн ишетәләр, һәр көн саен аның хуҗасы «мин» дип эндәшми. Аның урынына уң флангта басып торучы кызылармеец калын тавыш белән:

– Комсомолец Әнвәров Шамил, дошманнарны аяусыз кырып, Ватан даны өчен һәлак булды! – дип, еракларга ишетелердәй итеп кычкыра.» *(Музыка тына.)*

**1 а.б.**

Фашист Германиясе капитуляция ясаганнан соң солдатлар өйләренә кайтарыла башлагач та әле Габдрахман Әпсәләмовка хәрби хезмәтен Ерак Көнчыгыштa, япон милитаристларына каршы сугышта дәвам итәргә туры килә.

Казанга ул 1946 елның язында гына кайта.

Җиңү шатлыгы белән кайткан солдат, күрешү сөенече белән бергә, гаять зур югалту ачысын да кичерә. Татар әдәбияты сафы шактый сирәгәйгән, өлкән буын язучылар белән бергә бик күп, бик өметле яшь язучылар һәлак булган. Бу яшь каләмнәрнең таланты, өзелеп төшкән чәчәк кебек, ачылырга өлгерми кала, алар каләменнән төшәсе гүзәл әсәрләрне яшь буын укый алмый кала. Бары тик исемнәре генә истәлек такталарында, сугыштан соң әдәбиятка килгән әзтабарларның очеркларында, «Батырлар китабы»нда мәңгеләштерелә. Язучылар берлегенең Бауман урамындагы элеккеге бинасында, Тукай клубына кергән җирдә, мәрмәрташка алтын хәрефләр белән уеп Мифтах Вәдүт, Шамил Гәрәй, Мөсәгыйть Мостафин, Әгъзам Камал, Әхмәт Гыймадов, Исхак Закиров, Касыйм Вахит, Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Әхмәт Әминов исемнәре язылган иде. Бу истәлек тактасы янынннан үткәндә, Габдрахман Әпсәләмовның – нечкә күңелле әдипнең –ниләр кичергәнен күз алдына китереп була. Алар бит аның яшьтәшләре, әдәбият мәйданына бергәләп аяк баскан иптәшләре иде! Ул аларның дәртле тавышларын, кайнар бәхәсләрен ишеткән кебек булгандыр... Ә бер читтән, бераз көлемсери төшеп, аларның өлкәнрәк иптәшләре: Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Абдулла Алиш, Рахман Ильяс, Мөхәммәт Әблиев, Хәбра Рахман, Кәшфи Басыйров һәм башкалар карап тора сыман. Алар – үлемсезләр! Алар шулай ук сугыш кырыннан кайтмадылар...

Илгә исән-сау кайтуы өчен Г.Әпсәләмов ул батырлар алдында үзен бурычлы саный. Алар яза алмаган әсәрләрне язып калырга, алар ачарга өлгермәгән геройларны халыкка күрсәтергә, алар кичергән ватандарлык хисләрен яшь буынга тапшырырга ашыга ул.

**2 а.б.**

Язучы иҗатында роман жанры «Алтын йолдыз» романы белән башланып китә. Ул укучылар кулына сугыштан соң, 1948 елда килеп керә. Искиткеч матур, сокландыргыч образлары белән истә кала, рухландыра, тетрәндерә торган әсәр. Вакыйга сугыш чорында бара, үзәктә – яшьләр, төньяктагы диңгез сугышчылары, яшь егетләрнең беренче мәртәбә фронт чынлыгуы алулары...Әмма романда иң истә калганы – Галим Урманов образы, әле яңа гына урта мәктәпне тәмамлаган татар егетенең батырлыкка күтәрелү баскычлары...

Габдрахман Әпсәләмовның бу романы тиз арада рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителә, аларның да иң яраткан әсәрләреннән берсенә әверелә. Русча басылган китапның «Нинди матур! Какая прелесть!» – дигән иң беренче сүзләре үзләрендәге романтик аһәң, күтәренкелек дулкыны, пафос белән менә инде ничә дистә еллар укучыларны тылсымлап йөртә, яшәтә.

*(Укучы «Алтын йолдыз» әсәреннән өзек укый. Магнитофон аша әкрен генә симфоник оркестр башкаруында «Воспоминание» көе уйнатыла .)*

«Су асты көймәсе өскә күтәрелгәндә, якын-тирәдә дошман-

ның эзәрлекләүче корабльләре күренми, акустик диңгездә һичнинди шикле тавышлар ишетелми иде.

Һаваның дөньядагы бар нәрсәдән дә татлырак икәнен, аны күкрәк тутырып сулый алу чиксез зур бәхет икәнен белер өчен сәгатьләр буенча диңгез төбендә, кислороды бетеп барган кубрикларда ятарга кирәк икән. Су төбеннән күтәрелгән диңгезчеләр салкын һаваны сулап туя алмадылар. Отсектан рубкага чыккан Шалденко түзмәде, калынрак иреннәрен татуировкалы кул аркасы белән сыпырып алып, соры күзләрен кыса төште дә:

– Эх, татлы! – дип куйды, аннары кояшка каш сикертте, – яшибез, братишка!

Диңгез өсте беленер-беленмәс шадралана. Зюйд-ост җиле кайдандыр туфрак исен алып килә һәм бу туфрак исе озак еллар күмелеп торган йөзем эчемлеге кебек, тамырларга тагын да ләззәтлерәк рәхәтлек бирә.

Үлем куркынычыннан котылу кешеләрдә һәрвакыт катлаулы тойгылар уята. Рухы көчсез кешеләр ул куркыныч турында соңыннан, күп еллар үткәч искә төшергәч тә, сискәнеп куялар һәм яңадан шул куркынычка эләгүдән котлары оча. Рухы көчле кешеләр котылу шатлыгын тирәнрәк кичерәләр һәм, тормыш ямен кыенлыкларны җиңә белүдә күргәнлектән, яңа куркынычларга каршы тетрәмичә баралар.» *(Музыка тына.)*

**1 а.б.**

Г.Әпсәләмовның иҗаты берьюлы берничә юнәлештә бара. Әйтик, бер әсәре өстендә эшләгәндә, ул икенчесе өчен материал туплый, күңелендә инде өченче тема өлгереп килә. 1950 елда аның татар халкының данлы улы, Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин батырлыгына багышланган «Газинур» романы басылып чыга. Аннары ул тагын яңа әсәрләре өчен материаллар тупларга керешә. Әсәр язар өчен ул, кагыйдә буларак, тормыштан конкрет прототип эзли. Бухенвальд лагеренең бөтен дәһшәтләрен үз җилкәсендә татыган Бакый Назиров белән танышу, мәсәлән, аңа «Мәңгелек кеше» романын язуга этәргеч ясый.

*(Укучы «Мәңгелек кеше» әсәреннән өзек укый. Магнитофон аша әкрен генә Рөстәм Яхинның Муса Җәлил сүзләренә язылган «Соңгы җыр»ы уйнатыла.)*



«1944 елның 18 августка каршы болытлы бер төне иде. Крематорий ишек алдына өсте ябулы кара машина килеп туктады. Машина туктауга аннан штатский киемдәге ике кеше сикереп төште. Аларның кулларында пистолетлар тонык кына ялтырады. Шунда ук алар янына лагерь коменданты Кампе үзе йөгереп килде һәм нәрсәдер пышылдады. Штатский киемендәге кешеләр, машина эченә башларын тыгып, кемгәдер төшәргә боерык бирделәр. Куллары богауланган бер кеше, арты белән шуып, машинадан төште. Яланбашын күтәреп, крематорий морҗасыннан ургылып чыгып торган кызыл ялкынга карап алды, аннары карашын болытлар арасында бер күренеп, бер югалып торган айга һәм шул ай яктысында тирән кайгыга чумгансыман күренгән Гете имәненә күчерде. Имән башындагы корыган шәрә ботаклар ай яктысында ап-ачык күренә һәм алар крематорий морҗасыннан да шомлырак иде. Ләкин бу кешенең чиксез күп газаплардан тирән-тирән җыерчыклар белән капланган йөзе тыныч һәм кырыс, хәтта тантаналы иде. Ул гүя иске Германиянең корыйсын, яңасының туып киләсен күрә иде.» *(Музыка тына.)*

**2 а.б.**

Г.Әпсәләмов иҗатының тагын бер үзенчәлеге – аның халык авыз иҗаты җәүһәрләре булган мәкаль һәм әйтемнәрдән дә урынлы һәм уңышлы файдалана белүе. Билгеле булганча, мәкаль нинди дә булса вакыйга белән бәйле рәвештә искә төшерелә һәм аңарга ияреп килә. Шунда аның эчтәлеге ачыла, кыйммәте күренә, ягъни мәкаль, вакыйгасы белән бергә килгәндә генә, үзенең вазифасын үти ала. Г.Әпсәләмов аларны бик кирәк, стиль таләп иткән урында гына куллана. Әдип әсәрдәге әйтемнәрне әсәр тукымасын күркәмләү өчен генә түгел, төрле лексик мәгънәле сүзләрдә бирелгән төшенчәләрне көчәйтү, укучы күңеленә үтемле итү максатында да куллана. Алар персонажларның тормышын, яшәү рәвешен, шактый зур вакыйгаларны сурәтләүгә ярдәм итә.

Менә, мәсәлән, ул кулланган мәкальләрнең кайберләре:

«Илен белмәгән – игелексез, халкын белмәгән – холыксыз, нәселен белмәгән – нәселсез»

(«Агыла болыт»)

**1 а.б.**

«Туган илнең әреме дә татлы» («Агыла болыт»)

2 а.б.
«Шигъри сүз таулар күчерә» («Агыла болыт»)

1 а.б.
«Куркак көн дә үлә, батыр бер генә үлә» («Газинур»)

2 а.б.
«Гыйлем алу – инә белән кое казу» («Газинур»)

1 а.б.
«Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә» («Газинур»)

2 а.б.
«Дөя дә бүләк, төймә дә бүләк» («Газинур»)

1 а.б.
«Белгә юан берне егар, белеме юан меңне егар» («Газинур»)

2 а.б.
«Батыр егет – яу күрке» («Газинур»)

1 а.б.
«Ат аенда, ир елында саналыр» («Газинур»)

2 а.б.
«Ватаны юк – җыры юк сандугач ул» («Газинур»)

1 а.б.
«Сандугач җыры белән, ил – азатлыгы белән матур» («Газинур»)

2 а.б.
«Күп яшәгән ни белгән, күпне күргән шул белгән» («Газинур»)

1 а.б.
«Юлга чыкмас борын юлдаш сора, йорт салмас борын күрше сора» («Газинур»)



2 а.б.
«Ачык чырай – такта чәй» («Газинур»)

1 а.б.
«Йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып керә» («Газинур»)

2 а.б.
«Яудан соң батыр күбәя» («Мәңгелек кеше»)

1 а.б.
«Кая барсаң да, кара сакалын үзеңнән калмый» («Мәңгелек кеше»)

2 а.б.
«Урманның мең колагы бар» («Алтын йолдыз»)

1 а.б.
Заманында Г.Әпсәләмов исеменә «таш атучылар» шактый булган. Имеш, аның әсәрләре барысы да бертөсле, милли колорит юк: рус укыса, бу әсәр рус кешесе турында, үзбәк укыса, үзбәк турында һ.б.

Язучы иҗатына объектив бәяне шагыйрь Хәсән Туфан биргән: «Татар әдәбиятында иң авыр елларда Әпсәләм берүзе ун ел буена татар халкын татар теле янында тотып торды».

*(Укучы Хәсән Туфанның Г.Әпсәләмовка багышланган шигырен укый.)*

Читен чорда килдең, кадерлебез,
Иҗатка Син, алгы мәйданга:
Туган илнең китап киштәләре
Көтмәгәндә бушап калганда,
«Зәңгәр шәл»ләр җилгә очкан чорда,
«Безнең көннәр» мичтә янганда.

Күңел күзең күрде шул хәлләрне,
Күрде... Ләкин каушап калмадың:
Арганнарны алмаштырган сыман
Сафка басты азмы романың!

Һәм көттең Син, яза-яза көттең
Гадел көннәр, гадел чорларны:
Чыпта кәфендәге классиклар
Каберләрдән кайткан елларны.

Һәм алар да котлый бүген Сине:
– Сәлам сиңа, энебез Әпсәләм! –
Без кабызган утны сүндермәгән,
Дәвам иткән өчен, мәсәлән.

Зирәкләрчә җитез Синең талант,
Егетләрчә синең хәрәкәт:
Күз салам да Сиңа, шатланам мин:
Бәрәкәт Син, җанлы бәрәкәт!

Син никадәр күбрәк иҗат итсәң,
Син нихәтле балкып яшәсәң,
Үз телен дә сөючеләр саны
Нәкъ шулкадәр үсә, Әпсәләм.

Сокландыра Синең егетлегең,
Инфарктны да җиңә алуың,
Һәм маяклар санын арттыруда
Иң алдагы сафта баруың.

Моннан соң да шулай
Балкып яшәп,
Укучыңны ишәйт, Әпсәләм,
Күбәйт, җаным! –
Хәсән абыеңнан
Һәм наказ бу
Сиңа,
Һәм сәлам.

**2 а.б.**

Сугыш чорын һәм уңай геройларны тасвирлаганда автор еш кына куе романтик буяулар куллана. Мисал өчен «Алтын йолдыз»дан соң егерме ел үткәч язылган «Миңа унтугыз яшь иде» исемле повестьны алырга мөмкин. Бу повестьның да төп герое



Малик Газыймов искиткеч батырлыклар күрсәтә һәм, фашистлар кулына эләккәч, баш имичә, каһарманнарча үлә. «Алтын йолдыз» әсәрендәге Акбулатов үлемен тасвирлагандагы сәхифәләр кебек үк, аны җәзалау күренеше дә җете романтик буяулар белән сурәтләнә.

*(Укучы «Миңа унтугыз яшь иде» әсәреннән өзек укый. Магнитофон аша әкрен генә «Унике батыр турында баллада» җыры уйнатыла.)*

«Җәзалап та, кыйнап та сөйләтә алмагач, безне тышка сөйрәп чыгардылар. Монда зур учак яна иде.

– Я, соңгы мәртәбә сорыйбыз...

Мин эндәшмәдем. Мин тагы Мөслимә белән идем. «Бәгырем Малик, мин сиңа ышанам!» – диде ул. Әйе, әйе, ышан, Мөслимә! Мин алдамам, мин илемә турылыклы булып калырмын!

Мин шыпырт кына гитлерчыны дәшеп алдым.

– Миңа сөйләве авыр, иелә төшегез, әйтәм, – дидем.

Фашист тиз генә минем өстемә иелде. Мин аның кабахәт йөзенә лачт итеп төкердем дә:

Эт! – дидем.

Гитлерчы ачуыннан шартларга җитте, пистолетын суырып алды да миңа таба атып җибәрде. Ләкин мин һаман үлмәгән идем әле. Еракта безнең артиллерия үкерә башлавын ишеттем. Аның гөрелтесе тоташ бер тантанага әверелде. Гитлерчылар барысын да аңладылар булса кирәк, ашыгыч команда булды. Безне, ике совет кешесен, ялкынлы күккә сикереп торган зур учакка ташладылар.» *(Музыка көчәя һәм тына).*

**1 а.б.** Соңгы зур әсәрләреннән берсе булган «Агыла болыт» романында исә ул үзенең көрәштәш һәм каләмдәш дуслары Муса Җәлил һәм Гази Кашшаф образларына мөрәҗәгать итә. Әсәрдә авторның сугышта катнашуы, хәрби корреспондент булуы, фронт көндәлекләре язып баруы һәм гаять күп кичерешләре, күрелгәннәр аша туган хисләре хәлиткеч роль уйнаганлыгын да әйтергә кирәк.

*(Укучы «Агыла болыт» әсәреннән өзек укый. Магнитофон*

*аша әкрен генә Салих Сәйдәшевнең Муса Җәлил сүзләренә язылган «Сагыну» җыры уйнатыла.)*

«Алиш нәрсәнедер хәтерләргә тырышты. Колак төбендә әкрен генә бер көй чыңларга кереште. Кылт итеп шунда Муса көйләгән җыр исенә төште. Нинди җыр бу? Халык җырымы? Юк, халык җыры булса, Алиш аны беренче сүзеннән үк танып алыр иде. Бу җырны Алиш икенче тапкыр ишетә инде. Беренче тапкыр бу җырны икенче бер лагерьда бер әсир җырлаган иде.

– Нинди җыр, кем чыгарган? – дип сораган иде Алиш ул чакта.

– Нинди җыр икәнен белмим, абый, әмма йөрәккә үтә, хәтта тирәнтен актарып ала. Аны безнең кебек бер әсир чыгарган дип сөйләгәннәр иде. Гумеров фамилияле бугай.

Болай булгач, ул иң элек Мусаның җыры белән очрашкан түгелме соң? «Күр син аны, дөньяда ниләр була», – дип уйлады Алиш.

Кешеләр теге яки бу очрашу үзләренә киләчәктә нәрсә китерәсен алдан белми шул.

Алиш күңеле эзләгән язмышка таба икеләнүсез атлады. Тәрбиясендәге иң яхшы сыйфатлар хәрәкәткә килде. Сабый чагында Абдулла пионерда, үсә төшкәч, комсомол сафында тәрбияләнде. Бу тәрбия формаль булмаган, ул яшь җанның барлык күзәнәкләрен туендырган. Ул тыйнак, эш сөючән булып үсте, шапырынырга яратмады. Иҗаты өчен балалар әдәбиятын сайлавы да шуннан килмиме икән? Беркайчан да күзгә керергә, дан артыннан куарга тырышмады. Аның күңелендә нинди хисләр яшәвен әсирлектә язган бер шигыре бик ачык күрсәтә:

Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын,
Алтынны ул чүпкә генә санар,
Ин кыйммәтле күрер Ватанын.» *(Музыка тына).*

**2 а.б.**

Габдрахман Әпсәләмов озакка сузылган авырудан соң 1979 елның 7 февралендә Казанда вафат була.

**1 а.б.**

Ул, корыч каләмен үткен штыкка тиң итеп, җир йөзенә кояш



бәхет нурын сибеп торсын өчен дәһшәтле Бөек Ватан сугышы мәйданыннан киң иҗат юлына аяк басты һәм миллионлаган әдәбият сөючеләрнең тирән ихтирамын казанды. Аның исеме дә татар әдәбияты һәм матбугаты тарихында сүнмәс бер йолдыз булып балкыр.

*(Кичә ахырында залда утыручыларны җәлеп итеп, Г.Әпсәләмов әсәрләре буенча викторина үткәрергә, алдан төзеп әзерләнгән кроссвордны чишәргә мөмкин).*

(Кичә тәмам).

**Файдалану өчен чыганаклар:**


Грампластинкалар:

1. Воспоминание (Памяти жертв фашизма) [Звукозапись] / муз. Ф.Ахметова; исп. струн. гр. симфон. орк. филарм. Тат.-АССР им.Г.Тукая, дир.С.Калагин; Р.Абдуллин, орган // Симфоническая и хоровая музыка композиторов Татарии. – М., 1990. – С1029525007.

2. Моя республика [Звукозапись] / сл. Н.Арсланова; исп.хор академ.театра оперы и балета им. М.Джалиля; дир. Н.Джураева // Симфоническая и хоровая музыка композиторов Татарии. – М., 1990. – С1029525007.

3. Сагыну / Җәлил М. сүз.; С.Сәйдәшев көе; башк. М.Якупов // Сәйдәшев С. – М., 1991. – с1030943006.

4. Соңгы җыр / Җәлил М. сүз., башк. А.Аббасов; Р.Яхин (ф/но) // Песни и романсы М.Джалиля; Романсы из вокального цикла Р.Яхина. – М.:Мелодия. – 33Д – 16824.

5. Җырларым / Җәлил М. сүз.; башк. Р.Ибраһимова // Уйлану. – М.:Мелодия, 1988. – с6023801003.

6. Унике батыр турында баллада / Арсланов Н. сүз., Р.Яхин көе // Искусство народов СССР. Музыкальный Татарстан. – М: Мелодия. – 33Д – 032023.

Әдәбият:

1. Габдрахман Әпсәләмов сугышчан дуслары белән. Разведчик Габдрахман Әпсәләмов Карелия фронтында [Фотолар] // Ак чәчәкләр бүләк итте: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан, 2001. – Б 21.


Чыганак: Габдрахман Әпсәләмов: әдипнең тууына 100 ел тулуга багышланган методик-библиографик ярдәмлек / ТР Милли к-ханәсе; төз. Р.Р. Гаязова; җав. мөх-ре И. Г. Һадиев. - Казан : Милли китап, 2009. - 32 б.